Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

28 октябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамында дренаж торбасын төзекләндерү, Дербедень авылы таш юлларында чокырларны ремонтлау)? турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Дербедень авылы, Совет урамы, 32а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Э.Р. Морозова